# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **23. 11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенэ керүче Мәндей авылында 2020 елда үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндей авылында халык җыены карар бирә:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндей торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү.
2. Бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү

- Мәндәй авылы зиратын коймалау;
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Яңа ел, Җиңү көне, Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне)
- Мәндәй авыллында урам исемнәре язылган табличкалар ясату
- балалар һәм спорт мәйданчыгын төзекләндерү

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов